## ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Иске Минзәләбаш авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**2002 елның 21 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Иске Минзәләбаш авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Иске Минзәләбаш авылы территориясендә I төркем инвалидлардан, олы яшьтәге ялгыз гражданнардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлардан, хөкем ителгәннәрдән, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Иске Минзәләбаш торак пунктының Комсомол урамын ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, җәю,килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Иске Минзәләбаш торак пунктының урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

3) Иске Минзәләбаш торак пунктында Сабантуй бәйрәме үткәрү мәйданы территориясен төзекләндерү ( павильон сатып алу һәм урнаштыру, территорияне төзекләндерү өчен материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

4) Иске Минзәләбаш авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, Өлкәннәр көне, 9 Май, инвалидлар көне, спорт ярышлары ) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

5) Авыл җирлеге чикләрендә аншлаг язуларын ремонтлау (килешү буенча эшләр өчен түләү);

6) Җәйге чорда Иске Минзәләбаш торак пунктында территорияне чабу (Беларусь -320.4 маркалы тракторга ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, бензин белән эшли торган триммер сатып алу )

7) Иске Минзәләбаш торак пунктында юлларны кардан чистарту (Беларусь -320.4 маркалы трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

8) Иске Минзәләбаш торак пунктында чишмәләр территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу , юл салу, павильон сатып алу һәм урнаштыру, буяу, конструкцияләрне ремонтлау, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Иске Минзәләбаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче А.Н.Габдрахманов